ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 февраль 2023ел. № 534

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуны тану турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.17, 5.21 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Опекунга балигъ булган хокукка сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 1 октябрендәге 5912 номерлы;

2) «Опекунга, яшәү урынын алыштыру сәбәпле, опекага алынган затны яшәү урыны буенча исәптән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 1 октябрендәге 5914 номерлы;

3) «Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукына керергә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 1 октябрендәге 5915 номерлы;

4) «Балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5952 номерлы;

5) 2014 елның 22 августында «Челнинские известия» газетасының 62 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга

алдан рөхсәт бирү һәм аны залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында 2013 елның 2 октябрендәге 5952 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 13 августындагы 4752 номерлы;

6) 2017 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2017 елның 18 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 77 нче санында бастырып чыгарылган «Опекунга балигъ булган хокукка сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5894 номерлы;

7) 2017 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2017 елның 18 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 77 нче санында бастырып чыгарылган «Опекунга, яшәү урынын алыштыру сәбәпле, опекага алынган затны яшәү урыны буенча исәптән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5896 номерлы;

8) 2017 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2017 елның 18 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 77 нче санында бастырып чыгарылган «Балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5898 номерлы;

9) 2017 елның 4 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2017 елның 25 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 79 нчы санында бастырып чыгарылган «Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керергә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 октябрендәге 5905 номерлы;

10) 2018 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2019 елның 30 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 6 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5952 номерлы карары белән расланган балигъ булмаганнар катнашында кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 6680 номерлы;

11) 2018 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2019 елның 30 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 6 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5912 номерлы карары белән расланган опекунга балигъ булган хокукка сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 6685 номерлы;

12) 2018 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2019 елның 30 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 6 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5914 номерлы карары белән расланган опекунга, яшәү урынын алыштыру сәбәпле, опекага алынган затны яшәү урыны буенча исәптән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 6688 номерлы;

13) 2018 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2019 елның 30 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 6 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5915 номерлы карары белән расланган опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукына керергә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 6689 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов